| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ПСЕЕВСКОГОСЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

---

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**2020 елның 18 декабереннән** **№ 16**

Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлеге Советы
2020 елның 25 февралендәге
138 нче номерлы “Җир салымы турында "
карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТӘ:**

1. Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советы 2020 елның 25 февралендәге 138 нче номерлы “Җир салымы турында " карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә :

1.1. 4 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 4. Салым түләүче оешмалар өчен хисап чоры дип календарь елның беренче кварталы, икенче кварталы һәм өченче кварталы танылa.

Салым түләүче оешмалар өчен салым түләү агымдагы салым чорының беренче, икенче һәм өченче кварталларыннан соң узган хисап чорыннан соң килүче айның соңгы числосыннан да соңга калмыйча җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлешенең тиешле салым ставкасы ¼ күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла дип билгеләргә. Салым чоры йомгаклары буенча түләнергә тиешле салым суммасы узган салым чорыннан соң килүче елның 1 мартыннан да соңга калмыйча түләнә.»

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм www.mendeleevsk.tatarstan.ru Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтының "Песәй авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да соңга калмыйча үз көченә керә.

Песәй авыл җирлеге Советы Рәисе В.И. Мөхәммәтгалиев